**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 14 август № 589

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару, җир асты корылмаларын төзү һәм көнкүреш коеларын һәм скважиналарын ясау тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 февраль, 171 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару, җир асты корылмаларын төзү һәм көнкүреш коеларын һәм скважиналарын ясау тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару, җир асты корылмаларын төзү һәм көнкүреш коеларын һәм скважиналарын ясау тәртибен раслау турында» 2012 ел, 29 февраль, 171 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 30 июль, 646 нчы, 2014 ел, 22 май, 347 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир

хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару, җир асты корылмаларын төзү һәм көнкүреш коеларын һәм скважиналарын ясау тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару, җир асты корылмаларын төзү һәм көнкүреш коеларын һәм скважиналарын ясау тәртибе (алга таба – Тәртип) «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 19 статьясы, «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законының 29 статьясы нигезендә эшләнде һәм җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр, җир кишәрлекләрен арендалаучылар әлеге җир кишәрлекләре чикләрендә шартлату эшләрен кулланмыйча үз ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләре чикләрендә булган һәм дәүләт балансында исәпләнмәгән гомум таралган файдалы казылмалардан, үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү чыганаклары булмаган һәм үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү чыганагы булган су бирү горизонтлары өстендә урнашкан су горизонтларыннан чыгару күләме тәүлегенә 100 куб.метрдан артмаска тиеш җир асты суларыннан файдаланырга, шулай ук законнарда һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә биш метрга кадәр тирәнлектә җир асты корылмаларын төзергә хокукларын җайга сала.

Әлеге статья максатларында үз ихтыяҗлары өчен гомум таралган файдалы казылмалардан һәм җир асты суларыннан файдалану дигәндә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр, җир кишәрлекләрен арендалаучылар тарафыннан шәхси, көнкүреш һәм бүтән эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру белән бәйле булмаган ихтыяҗларда файдалану күздә тотыла.

Җир кишәрлекләре чикләрендә булган һәм җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр, җир кишәрлекләрен арендалаучылар тарафыннан шәхси, көнкүреш һәм бүтән эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру белән бәйле булмаган ихтыяҗларда файдаланылган гомум таралган файдалы казылмалар һәм җир асты сулары тартып алына һәм бер заттан икенчесенә күчә алмый.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\589.docx